**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№7743**
**24.12.2018**

2019 елга Яр Чаллы шәһәре торак фондының торак урынынан файдалану өчен түләү (наем өчен түләү), торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләме турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 маддәсенең 3, 4 бүлекләре, 158 маддәсенең 4 бүлеге, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 нче карары белән расланган Күп фатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләренең 31, 36 пунктлары, Россия Федерациясе Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 6 апрелендәге 213/пр санлы приказы белән расланган күп фатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында карар, торак урынны карап тотуга түләү күләме билгеләү турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга түләү күләмен билгеләү буенча, шулай ук шундый түләү күләмен үзгәртүнең чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү буенча методик рекомендацияләр, Россия Федерациясе Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 27 сентябрендәге 668/пр санлы приказы белән расланган дәүләт яки муниципаль торак фондының торак биналарын наемга алучылар өчен торак урыннарыннан файдалануга түләү күләмен билгеләү буенча методик күрсәтмәләр, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә, халык хокукларын һәм ихтыяҗларын яклау системасының нәтиҗәлелеген күтәрү чаралары турында» 2010 елның 19 февралендәге 85 нче карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкка күрсәтелә торган торак һәм коммуналь хезмәтләрнең сыйфатын күтәрү чаралары һәм алар өчен түләү күләменең нигезле булуы турында» 2010 елның 9 апрелендәге 250 нче карары, Башкарма комитетның 2017 елның 26 декабрендәге 8125 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең социаль наем килешүләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак биналарын наемга алу килешүләре буенча торак биналарны наемга алучылар өчен торак урыннан файдалануга түләү (наем өчен түләү) күләмен исәпләү турында нигезнамә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Социаль наем килешүләре һәм дәүләт һәм муниципаль торак фондының торак биналарын наемга алу килешүләре буенча торак биналарны наемга алучылар

өчен торак урыннарыннан файдалануга түләү (наем өчен түләү), торак урынны карап тотуга һәм ремонтлауга түләү күләмен һәм күп фатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында карар һәм (яки) торак урынны карап тотуга түләү күләме билгеләү турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга түләү күләмен кушымтада каралганча билгеләргә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертергә.

2. Күп фатирлы йорттагы торак урынны карап тоту өчен түләү күләме торак урынны карап тоту буенча күрсәтелә торган хезмәтләр составына һәм күп фатирлы йортның конструктив үзенчәлекләренә бәйле рәвештә исәпләнүне һәм үзгәртелүне билгеләргә.

3. Торак бинаны наемга алу өчен түләү күләме, Башкарма комитетның 2017 елның 26 декабрендәге 8125 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең социаль наем килешүләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак биналарын наемга алу килешүләре буенча торак биналарны наемга алучылар өчен торак урыннан файдалануга түләү (наем өчен түләү) күләмен исәпләү турында нигезнамәдә каралган коэффициентларны кулланып, торак бинаның сыйфатына һәм төзекләндерелүенә, йортның урнашу урынына бәйле рәвештә билгеләнә.

4. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) Башкарма комитетның «2018 елга Яр Чаллы шәһәре торак фондының торак урыныннан файдалану (наем өчен түләү), торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләме турында» 2017 елның 25 декабрендәге 8084 нче карары;

2) Башкарма комитетның «Башкарма комитетның «2018 елга Яр Чаллы шәһәре торак фондының торак урыныннан файдалану (наем өчен түләү), торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләме турында» 2017 елның 25 декабрендәге 8084 нче карарына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 28 июнендәге 3682 нче карары.

5. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

6. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 24 декабрендәге
7743 нче карарына
кушымта

| Т/с | Түләү исеме | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге | 01.01.2019 елдан хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тариф (сумнарда) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Торак бинаны наемга алу өчен түләүнең база күләме | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 6,14* |
| 2. | Торак фонд белән идарә итү | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 2,85 |
| 3. | Гомуми файдалану урыннарының санитар торышы, шул исәптән: | | |
| 3.1. | - йорт эчендәге гомуми файдалану урыннарын җыештыру | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 1,85 |
| 3.2. | - йорт яны территориясен җыештыру | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 2,45 |
| 3.3. | - чүп үткәргечләргә хезмәт күрсәтү | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 1,45 |
| 3.4. | - дератизация (дезинсекция) | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 0,16 |
| 4. | Төзелеш корылмаларын һәм биналарның инженерлык системаларын ремонтлау һәм техник хезмәт күрсәтү, шул исәптән: | | |
| 4.1. | - торак биналар һәм йорт яны территориясен төзекләндерү | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 3,30 |
| 4.2. | - лифтлар | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 3,40 |
| 4.3. | - йорт эчендәге электр челтәрләре һәм электр җиһазлары | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 0,92 |
| 4.4. | - йорт эчендәге газ челтәрләре | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 0,27 |
| 4.5. | - йорт эчендәге су белән тәэмин итү һәм канализация системалары (бойлер булмаган) | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 2,23 |
| 4.6. | - йорт эчендәге су белән тәэмин итү һәм канализация системалары | аена гомуми торак | 2,77 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | (бойлер булган) | мәйданының кв.м | |
| 4.7. | - йорт эчендәге үзәктән җылыту челтәрләре | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 2,78 |
| 4.8. | телевидениене коллектив кабул итү системалары (СКПТ) (хезмәт күрсәтелгән очракта) | хезмәт күрсәтелгән очракта, аена гомуми торак мәйданының кв.м | 0,55 |
| 4.9. | - янгынга каршы автоматика системасы (хезмәт күрсәтелгән очракта) | хезмәт күрсәтелгән очракта, аена гомуми торак мәйданының кв.м | 1,05 |
| 4.10. | - домофоннар | хезмәт күрсәтелгән очракта, аена фатирдан | 25,00 |

* - Түләүнең туры килү коэффициентын исәпкә алып

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова